| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.12.2019 Казан шәһәре № 473

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Гражданнардан һәм оешмалардан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына килгән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру тәртибе турында» 2015 елның 20 июлендәге 201 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 30 сентябрендәге 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары чыгарылуга бәйле рәвештә

б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) «Гражданнардан һәм оешмалардан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына килгән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру тәртибе турында» 2015 елның 20 июлендәге 201 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«3. Мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлегенә күрсәтелгән анализны Дәүләт комитетының рәсми сайтында гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре буенча хисаплар һәм мәгълүмат алынганнан соң өч көн эчендә урнаштыруны тәэмин итәргә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары С.В.Павловка йөкләргә.»;

Әлеге боерык белән расланган Гражданнардан һәм оешмалардан Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына килгән мөрәҗәгатьләргә анализ уздыру тәртибендә:

6-7 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Бүлек башлыгы 3 пунктта күрсәтелгән, шулай ук әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә кергән мәгълүматны гомумиләштерә һәм анализлый, кергән көннән алып 2 эш көне эчендә анализны Бүлекне җитәкли торган рәис урынбасары белән килештерә.

7. Мөрәҗәгатьләрне анализлау Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру өчен мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлегенә җибәрелә. Анализ Дәүләт комитетының рәсми сайтында гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре буенча хисаплар һәм мәгълүмат алганнан соң 3 көн эчендә урнаштырыла.».

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары С.В.Павловка йөкләргә.

Рәис А.С.Груничев